**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОКАДЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Советская ул, 51, с.Утыз Имян ,423109

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 51, Утыз Имән авылы, 423109

тел.(884396) 2-01-45 факс (884396) 2-01-45 email: Nkad.Cmn@tatar.ru

**№29** **15 декабрь 2025 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә һәм шәһәр һәм авыл җирлекләренең бухгалтерлары хезмәт хакын түләү турында» 2025 елның 27 октябрендәге 03-12/7278 номерлы хатын үтәү йөзеннән, авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 7 номерлы карарына (2022 елның 25 ноябрендәге № 19, 2023 елның 1 февралендәге № 4, 2024 елның 20 июнендәге № 10, 2024 елның 18 декабрендәге № 20, 2025 елның 31 апрелендәге № 16 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Яңа Кади авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмә»нең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Баш бухгалтерның хезмәт хакы 31000,00 сум (Утыз бер мең сум) күләмендә билгеләнә».

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме һәм шул ук квалификациядәге эшләр башкарылуы сакланып калганда, хезмәткәрләрнең хезмәт хакының әлеге карар нигезендә билгеләнә торган күләме 2025 елның 31 декабренә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Яңа Кади авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесе М.М.Әминов